ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**23.10.2018**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 2155**

Җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертүне раслау турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2011 елның 28 мартындагы 437 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 27 июлендәге 1565 номерлы карары белән расланган җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр...» абзацыннан соң 1.5 пунктын «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгенең читтән торып эш урыны - муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү һәм тапшыру, консультация бирү тәрәзәсе» һәм «техник хата– муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән белешмәләрнең (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең) документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә китергән хата (хата, ялгыш, грамматик яки арифметик хата яки шундый хата);;

1.2. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының 2.4 пунктында

«Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктату каралмаган» абзацын өстәргә;

1.3. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктында текст ахырында түбәндәгеләрне өстәргә: «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетта (Департаментта) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшыра (җибәрә) ала:

шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);

почта аша.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

1.4. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында 2.6 пунктны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә: «Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык булган мәгълүматлар).

Төзелешкә рөхсәттәге булган белешмәләр.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.

3) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алда әйтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмау аңа хезмәт күрсәтмәү өчен нигез булып тормый»;

1.5. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы 2.13 пунктны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә: «Гариза килгәннән соң бер көн эчендә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң киләсе эш көнендә теркәлә»;

1.6. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы 2.13 пунктта «Муниципаль хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер мәртәбә үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла» текстлы абзацны өстәргә. Аралашу озынлыгы регламент белән билгеләнә»;

1.7. 3.4.1 пунктынының 1)пунктчасын түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә: «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык белешмәләр булган)»;

1.8. 3.4.2 пунктны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә: «Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр соратып алына торган документларны (мәгълүматларны) тапшыралар яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә гамәлгә ашырыла:

- Росреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (белешмәләр) буенча – өч эш көненнән артмый;

калган тәэминатчылар буенча-органга яки оешмага ведомствоара рәсми мөрәҗәгать кергән көннән биш көн эчендә, әгәр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатькә җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнмәсә.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яисә Департаментка җибәрелгән баш тарту турында хәбәрнамә»;

1.9. 5.1 пунктындагы 2 ) пунктчасын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

«Күрсәтелгән очракта күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин, әгәр күп функцияле үзәк хезмәткәренә шикаять белдерелә торган күп функцияле үзәккә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса »;

5) пунктчага түбәндәге абзац өстәргә:

«Күрсәтелгән очракта күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин, әгәр күп функцияле үзәк хезмәткәренә шикаять белдерелә торган күп функцияле үзәккә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса »;

7 )пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең җибәрелгән басма хаталарны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозудан баш тартуы.

Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү мөмкин, әгәр шикаять ителә торган күп функцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса»;

түбәндәге текстлар белән кабат 8) һәм 9 пунктчалар кертергә:

8) дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү мөмкин, әгәр шикаять ителә торган күп функцияле үзәккә, аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса.

2. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С.Анисимовка әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы порталы составындагы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.А. Сапожников